Республика Татарстан
Лякинское сельское поселение
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районының Ләке авыл
жирлеге

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

«29» января 2024 г.

КАРАР

№ 1

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
«Ләке авыл җирлеге» муниципаль
берәмлегендә җирләү буенча
хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы N 8-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы N 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты түбәндәгеләрне кертә:

1.2024 елның 1 февраленнән башлап җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә Сарман муниципал районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 8370,20 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү һәм гамәлгә кертү

2. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Сарман

муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муницпаль районы
Ләке авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ю.Г.Антонов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

Хезмәт күрсәтү исеме	Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)
1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү	-
2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү	4971,19
3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү	1748,65
4. Җирләү (кабер казу һәм күмү)	1650,36
Барлыгы	**8370,20**

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2024 елның 29 гыйнварындагы 1
номерлы карарына 2 нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

Хезмәт күрсәтү исеме	Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.)
1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү	-
2. Кәфенләү	1568,46
3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү	3402,73
3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү	1748,65
5. Җирләү (кабер казу һәм күмү)	1650,36
Барлыгы	8370,20